ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

23 май 2019ел

**КАРАР**

№ 2663

Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 24 июнендәге 3237 нче, 2016 елның 13 декабрендәге 6675 нче, 2017 елның 8 февралендәге 588 нче, 2017 елның 3 маендагы 2747 нче, 2017 елның 28 сентябрендәге 5805 нче, 2018 елның 18 июлендәге 4000 нче, 2018 елның 27 июлендәге 4226 нчы, 2018 елның 2 августындагы 4343 нче, 2018 елның 22 ноябрендәге 6940 нчы, 2019 елның 5 мартындагы 1144 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегендә:

- 51 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«51. Коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзасы булып торган гражданга җир участогын бушлай бирү.»;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлегендә:

- 25 пунктта «бүлеге» сүзен «бүлекләре» сүзенә алмаштырырга;

- 28 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«28. Гражданнар хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклыклар бирү.» ;

- түбәндәге эчтәлектәге 29-34 пунктлар белән тулыландырырга:

«29. Тууны дәүләт теркәвенә алу.

30. Үлүне дәүләт теркәвенә алу.

31. Уллыкка (кызлыкка) алуны дәүләт теркәвенә алу.

32. Ата булуны билгеләүне дәүләт теркәвенә алу.

33. Исем алмаштыруны дәүләт теркәвенә алу.

34. Гражданнар хәле актлары язуларына төзәтмәләр һәм үзгәрешләр кертү.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин